ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.02.2024 ел Баулы шәһәре №14

"Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында” Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 октябрендәге 213 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифралы платформа” дәүләт мәгълүмат системасы турында” 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында” Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 октябрендәге 213 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

5 пунктка түбәндәгечә өстәргә:

“5. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге МКУ начальнигы Д.З.Ганиевага “Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа” (алга таба – БҮП) дәүләт мәгълүмат системасында социаль ярдәм чаралары турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм БҮП операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә җибәрүне (урнаштыруны) тәэмин итәргә.”.

5 һәм 6 пунктларын 6 һәм 7 пунктлары итеп санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров